КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 гыйнвар г.Казань № 1

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 август, 756 нчы карары белән расланган Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август, 756 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 июнь, 558 нче; 2023 ел, 6 февраль, 107 нче; 2023 ел, 13 май, 589 нчы; 2023 ел, 22 июнь, 736 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка

чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2023 елда «Татарстан Республикасының «Елның иң яхшы яшь укытучысы» республика конкурсы» республика чарасында җиңүчеләрне акчалата бүләкләү.»;

түбәндәге эчтәлекле $19^2$ пункт өстәргә:

«$19^2$. «Татарстан Республикасының «Елның иң яхшы яшь укытучысы» республика конкурсы» республика чарасын үткәрү чыгымнарын каплау максатында субсидия күләме (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = (З_1 + З_2 + З_3 + ... + З_n) + М_1 + М_2 + М_3,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, $З_3$, ..., $З_n$ – әлеге Тәртипнең 9 пунктындагы икенче – унсигезенче, егерменче, егерме икенче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар;

$М_1$ – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган «Татарстан Республикасының «Елның иң яхшы яшь укытучысы» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә каралган, 2023 елда «Татарстан Республикасының «Елның иң яхшы яшь укытучысы» республика конкурсы» республика чарасында беренче урынны алган җиңүчегә акчалата бүләкләү күләме;

$М_2$ – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган «Татарстан Республикасының «Елның иң яхшы яшь укытучысы» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә каралган, 2023 елда «Татарстан Республикасының «Елның иң яхшы яшь укытучысы» республика конкурсы» республика чарасында икенче урынны алган җиңүчегә акчалата бүләкләү күләме;

$М_3$ – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган «Татарстан Республикасының «Елның иң яхшы яшь укытучысы» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә каралган, 2023 елда «Татарстан Республикасының «Елның иң яхшы яшь укытучысы» республика конкурсы» республика чарасында өченче урынны алган җиңүчегә акчалата бүләкләү күләме.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин